КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 25 декабрь г.Казань № 1189

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 6 июль, 561 нче номерлы карары белән расланган Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чараларны тормышка ашыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәм-лекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чараларны тормышка ашыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмә-ләрен финанслашу өчен Татарстан Респуб-ликасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 6 июль, 561 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 18 ноябрь, 1032 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чараларны тормышка ашыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Респуб-ликасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы

бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта «авария хәлендәге торак фонды» сүзләреннән соң «, күпфатирлы йортларның авария хәленә бәйсез экспертиза уздыру» сүзләрен өстәргә;

7 пунктка түбәндәге эчтәлекле «и» пунктчасын өстәргә:

«и) күпфатирлы йортларның авария хәленә бәйсез экспертиза уздыруга карата - аларга карата бәйсез экспертиза үткәрелгән авария хәлендәге күпфатирлы йортлар саны.»;

9 пунктка түбәндәге эчтәлекле «з» пунктчасы өстәргә:

«з) күпфатирлы йортларның авария хәленә бәйсез экспертиза үткәрүгә карата түбәндәге формула буенча:

$$P_i = \sum K \times N \times M,$$

монда:

K - авария хәленә бәйсез экспертиза ясалырга тиешле авария хәлендәге күпфатирлы йортлар саны;

N - тиешле муниципаль берәмлектә уртача базар бәясе буларак билгеләнә торган күпфатирлы йортларның авария хәленә бәйсез экспертиза уздыру бәясе.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин